КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 сентябрь г.Казань № 752

2019 елда цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсация бирү чыгымнарын финанслау тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасында цифрлы телевидение тапшыруына күчкәндә гражданнарның социаль яклanмаган категорияләренә адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2019 елда цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсация бирү чыгымнарын финанслау тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 2 сентябрь, 752 нче
карары белән расланды

2019 елда цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсация бирү чыгымнарын финанслау
тәртибе

1. Бу Тәртип 2019 елда цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсацияләр (алга таба – компенсация) бирү чыгымнарын финанслау механизмын билгели.

2. Компенсация түләү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) ай саен, агымдагы елның 8 енә кадәр, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына компенсацияләр бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә заявка (алга таба – заявка) җибәрә.

4. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы ай саен аның заявкалары буенча Министрлыкка финанслауның иң чик күләмнәрен ирештерә.

5. Министрлык ай саен, финанслауның иң чик күләмнәре Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан ирештерелгәннән соң биш эш көне эчендә, алга таба гражданнарның банкта яки башка кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына күчерү өчен аларны «Автоматлаштырылган тикшерү үзәге – Финанслар» («АЦК – Финансы») системасы аша электрон төрдә боерык характерындагы заявка рәвешендә «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба – Үзәк) күчерә.

6. Үзәк ай саен, хисап чорыннан соң килүче айның 10 ысыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджетыннан башкарылган чыгымнар турындагы мәгълүматны Министрлыкка кертә.

7. Министрлык ай саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15 еннән дә соңга калмыйча, компенсация алучылар санын күрсәтеп, Татарстан Республикасы бюджетыннан башкарылган чыгымнар турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына кертә.

8. Министрлык һәм Үзәк кертелә торган хисап мәгълүматлары дөрес булмаган һәм акчаны максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җавап бирә.

9. Бу Тәртип нигезендә бирелгән акчаның максатчан файдалануын тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.